Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

26 май 2020 ел № 675

Җир кишәрлегеннән һәм капиталь
төзелеш объектыннан шартлы рөхсәт
ителгән рәвешкә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2015 елның 30 сентябрендәге «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 709 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 26 декабрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре, «гавами тыңлаулар билгеләү турында» Әлмәт муниципаль районы башлыгының 2019 елның 21 августындагы 67 номерлы карары нигезендә үткән 2019 елның 25 ноябрендәге 9360и номерлы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, беркетмә нигезендә («Альметьевский вестник» газетасында басма, 12 декабрь, 2019 ел, № 51),

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге, Кама-Исмәгыйль авылы, Тукай ур., җ/к 20 адресы буенча урнашкан Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын код № 5.1 «спорт мәйданчыгы» кулланының шартлыча рөхсәт ителгән төренә, җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча төзелүче җир кишәрлегенә карата 1317 кв.м мәйданлы «спорт» кодына рөхсәт бирергә.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов